МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.09.2021 г. Казань № под-1200/21

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезендә боерык бирәм:

1. Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын раслау турында» 2020 елның 8 апрелендәге под-513/20 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (В.О.Васильева) боерыкны имзалаганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М.Әсәдуллнага йөкләргә.

Министр И.Г. Һадиуллин

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән
министрлыгының 2021
елның 17.09.
№ под-1200/21 боерыгы
белән расланды

**Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып уллыкка алучылар, опекуннар (попечительләр), тәрбиягә бала алган ата-аналар тора, түбәндәгеләр исәбеннән:

а) Россия Федерациясе территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары;

б) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар, шулай ук качаклар;

в) Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча яшәүче һәм чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның вакытлыча эшкә яраксызлык очрагына һәм ана булуына бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминиятләштерелергә тиешле затлар;

г) контракт буенча хәрби хезмәт узучы, эчке эшләр органнарында, милли гвардия гаскәрләрендә, Янгынга каршы дәүләт хезмәтендә, җинаять үтәтү системасы учреждениеләрендә һәм органнарында, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарында, таможня органнарында рядовой һәм җитәкче состав һәм, мондый пособиеләрне түләү Россия Федерациясенең халыкара килешүләрендә каралган очракларда, чит ил территорияләрендә булган Россия Федерациясе хәрби формированиеләренең гражданлык персоналы сыйфатында хезмәт узучы Россия Федерациясе гражданнары.

1.2.1. Мөрәҗәгать итүчеләр исеменнән Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышаныч кәгазе нигезендә гамәл кылучы затлар эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: ТР, Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 3 йорт, 205, 207 кабинетлар.

Министрлыкның эш графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбедән тыш, дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.30 сәгатьтән 13.30 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбедән тыш, дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш 12.30 сәгатьтән 13.30 сәгатькә кадәр.

Җәмәгать транспортында «Ирек мәйданы», «КАИ», «Үзәк стадион» тукталышына кадәр килергә кирәк.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Белешмәләр өчен телефоннар: 294-95-67, 294-95-18.

1.3.3. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Министрлык һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – күпфункцияле үзәк) урнашкан урын һәм аларның эш графигы турындагы мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлыкның һәм күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан мәгълүмат стендлары аша.

Стендта Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.mon.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы).

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал);

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба – Республика реестры);

Бердәм порталда, Республика порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла;

3) Министрлыкка телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ формасында да) мөрәҗәгать иткәндә;

5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәккә (алга таба – күпфункцияле үзәк) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация бирү түбәндәгеләрдә гамәлгә ашырыла:

1) Республика порталының интерактив формасында;

2) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

3) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә;

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәккә (алга таба – күпфункцияле үзәк) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.3. Мнистрлыкның, КФҮ, КФҮ ерактагы эш урынының урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почтасы адресы турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында, Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган.

Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында, мөрәҗәгать итүче белән эшләү өчен Министрлык бүлмәләрендә урнашкан мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүматларны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Республика реестрында урнаштырылган.

1.5. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт хезмәте – федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының, җирле үзидарә органының функцияләрен тормышка ашыру эшчәнлеге, ул дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән вәкаләтләре чигендә мөрәҗәгать итүчеләрнең рәсми мөрәҗәгатьләре буенча гамәлгә ашырыла;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе бозылуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешмалар һәм аларның хезмәткәрләре тарафыннан мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алганда бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында таләп итүе;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге (күпфункцияле үзәк, КФҮ) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автоном учреждение булып торган), 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм,

шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

«бер тәрәзә» принцибы – дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле мөрәҗәгать белән яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 151 статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать белән бер мәртәбә мөрәҗәгать иткәннән соң гамәлгә ашырыла торган, ә дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнар яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар белән хезмәттәшлек итү мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка гына, норматив хокукый актларга һәм хезмәттәшлек итү турында килешүгә туры китереп күпфункцияле үзәк аша гамәлгә ашырыла торган принцип;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

ИАБС – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы;

Автоматлаштырылган мәгълүмат системасы – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләренең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата);

опека – опека һәм попечительлек органы билгеләгән гражданнар (опекуннар) үзләре тәрбиягә алган балаларның законлы вәкилләре булып тора торган һәм алар исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрендә юридик әһәмияткә ия барлык эшләрне башкара торган итеп кече яшьтәге (ундүрт яшенә җитмәгән балигълык яшенә җитмәгән гражданнарны) гражданнарны урнаштыру формасы;

попечительлек – опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданин (опекун) әлеге затларга үз хокукларын гамәлгә ашыруда һәм бурычларын үтәүдә, шулай ук өченче затлар ягыннан алардан явыз ниятта файдаланудан саклауды булышлык күрсәтергә бурычлы булырлык итеп ундүрт яшьтән олырак балигълык булмаган гражданнарны урнаштыру формасы;

тәрбиягә бала алган гаилә – опека һәм попечительлек органы белән баланы тәрбиягә ала торган ата-аналар яки тәрбиягә ала торган ата-ана белән төзелә торган килешүдә срокка төзелә торган, тәрбиягә алучы гаилә турындагы килешү буенча балага яки балаларга карата гамәлгә ашырыла торган опека яки попечительлек;

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон)). Гариза формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтенең исеме: «Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособиене түләү».

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның исеме: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турында карар (2 нче кушымта);

2) баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие түләү;

3) баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләүдән баш тарту турында карар (3 нче кушымта).

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү гаризаны барлык кирәкле документлар белән кабул иткән (теркәгән) көннән соң 10 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

2.4.2. Пособие федераль почта элемтәсе оешмасы яки пособие алучылар тарафыннан гаризада күрсәтелгән кредит оешмалары аша түләнә.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.4. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта буенча, электрон адреска яки смс-хәбәр итеп) җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

2.5. Закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе.

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) гариза:

күпфункцияле үзәккә, Министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә, кәгазь документ формасында (1 нче кушымта);

Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткән очракта, Регламентның 2.5.2 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла).

2) гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) уллыкка алу турында суд карары күчермәсе яки опека һәм попечительлек органы карарыннан балага опека (попечитель) билгеләү турында, шул исәптән тәрбиягә бала алган гаилә турында килешү буенча да, өземтә;

2) инвалидлык билгеләү фактын раслаучы белешмә – инвалид баланы уллыкка алган затлар өчен;

3) балаларның туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документлар – бертуган ир һәм (яки) кыз туганнарны уллыкка алган затлар өчен.

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү өчен, опека (попечитель) билгеләнгән очракта яки тәрбиягә алучы гаиләгә тапшырылганда, ата-аналарның (бердәнбер ата-ананың) булмавын яки алар (аның) тарафыннан балаларны тәрбия кылу мөмкинлеге булмавын раслый торган тиешле документларның күчермәләре өстәмә рәвештә тапшырыла:

1) чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән, ата-ананың үлемен дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкларның күчермәләре һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

2) ата-ана хокукыннан мәхрүм итү (ата-ана хокукларын чикләү турында), ата-аналарны эшкә сәләтсез (чикләнгән рәвештә эшкә сәләтсез), билгесез югалган яисә вафат булган дип тану турында суд карары;

3) эчке эшләр органыннан яисә опека һәм попечительлек органыннан бирелгән, табылдык (ташлап калдырылган) баланы табу турында документ;

4) билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән баланың уллыкка (кызлыкка) алынуына ризалык турында ата-аналар гаризасы;

5) балага ата-ана тәрбиясенең булмавы (шул исәптән ата-ананың авыруына бәйле рәвештә дә) фактын билгеләү турында яки бала туу турындагы акт язуыннан ата-ана(лар) турындагы белешмәләрне төшереп калдыру турында суд карары;

6) шәхесен таныклый торган документны күрсәтмәгән ананың баласын бала туган һәм бала тудырганнан соң ана кеше мөрәҗәгать иткән медицина оешмасында калдырып китүе турында акт;

7) «ана» һәм «ата» юлларында сызык куелган, чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән тууны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аның рус теленә нотариаль таныклыгын тәрҗемәсе.

Даими рәвештә Россия Федерациясе территориясендә яшәүче, Россия Федерациясендә вакытлыча яши торган һәм вакытлыча эшкә сәләтле булмау һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминиятләштерүгә тиешле чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар, шулай ук качаклар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

1) шәхесне таныклый торган документ күчермәсе, шул исәптән яшәргә рөхсәт бирелүе турында тамга белән;

2) вакытлыча яшәү өчен рөхсәт күчермәсе;

3) хезмәт кенәгәсенең тиешле рәвештә расланган күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66[1] статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр яки тиешле тәртиптә таныкланган хезмәт килешүе күчермәсе;

4) качак таныклыгы күчермәсе.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (алга таба – Бүлек) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырыла (җибәрелә):

шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);

кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы аша.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гариза һәм теркәлә торган документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, Бердәм портал, Республика порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасындагы документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

2.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, гариза гади электрон имза белән имзалана.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

2.5.3. Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле килештерүләрне дә кертеп, һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итүгә

бәйле гамәлләр башкаруны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән исемлекләргә кертелгән хезмәтләрне күрсәтү һәм әлеге хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсендә бирелә торган документларны һәм мәгълүматларны алудан (кирәкле һәм мәҗбүри күрсәтелә торган хезмәтләрдән) тыш;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза бирүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

в) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартылганнан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренчел баш тарткан очракта опека һәм попечительлек органы вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең ялгыш яки хокукка каршы килә торган гамәлләр башкаруы (гамәл кылмавы) буенча документ нигезендә расланган факты (билгеләре) булуы ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренчел баш тарткан вакытта опека һәм попечительлек органы җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә мөрәҗәгать итүчегә бу хакта хәбәр ителә, шулай ук әлеге уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә;

4) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре танықланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма.

2.6.1. Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында вәкаләтле органнардан түбәндәге документлар һәм түбәндәгеләрне раслый торган белешмәләр алына:

1) Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактлары булуын яки булмавын раслый торган белешмәләрнең һәм башка төрле документларның формаларын һәм Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактлары булуын яки булмавын раслый торган белешмәләр һәм башка төрле документларның формаларын тутыру кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 1 октябрендәге 200 номерлы боерыгы белән расланган 2 номерлы форма буенча туу турында белешмә;

2) балигъ булмаган баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында;

3) балигъ булмаган баланың ата-анасы үлемен дәүләт теркәвенә алу турында;

4) аерылышуны (яки өйләнешүне) дәүләт теркәвенә алу турында;

5) атаны билгеләүне дәүләт теркәвенә алу турында;

6) Эчке эшләр органнарыннан эзләнә торган ата-ананың урнашу урыны билгеләнмәгәнлеге турында белешмә.

7) балага айлык пособие түләүне туктату турында халыкны социаль яклау буенча территориаль орган белешмәсе (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан);

8) Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органыннан иминиятләштерүче сыйфатында Фонд органнарында теркәү турында белешмә яки качак таныклыгы күчермәсе (Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге дәүләт учреждениесеннән);

9) инвалидлык билгеләү фактын раслаучы белешмә – инвалид баланы уллыкка алган затлар өчен (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

10) баланың яшәү урыныннан аның опекун (попечитель), тәрбиягә алган ата-аналары белән бергә яшәве турында белешмә (РФ Эчке эшләр министрлыгыннан);

Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

2.6.2. Гариза Республика порталы, Бердәм портал аша тапшырылган очракта мөрәҗәгать итүче Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларны (белешмәләрне), мондый документларны төзү һәм имзалауга вәкаләтле затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән таныкланган электрон документлар формасында яки күпфункцияле үзәккә яки Министрлыкка кәгазь чыганакта тапшырырга хокуклы.

2.6.3. Әлеге дәүләт хакимияте органнары тарафыннан документлар һәм мәгълүматның тапшырылмавы (вакытында тапшырылмавы) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе була алмый.

2.6.4. Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

2.6.5. Мөрәҗәгать итүчедән, дәүләт хезмәте күрсәтелгән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торганнарын да исәпкә алып, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагында булган документларны һәм мәгълүматларны тапшыруны таләп итү тыела.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту (документларны асылы буенча карамыйча кире кайтару) нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

2) гариза формасында, шул исәптән Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның интерактив формасында, кырларның тулысынча тутырылмавы;

3) Россия Федерациясе законнары нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең исемлеге тулы булып тора.

2.7.3. Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар мөрәҗәгать итүчене кабул итү вакытында да, Министрлыкның вазыйфаи заты ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) алганнан соң да гаризаны теркәгән көннән соң 7 эш көненнән артмаган срокта кабул ителә ала.

2.7.4. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда, Республика порталында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

1) мөрәҗәгать итүченең әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән категорияләргә карамавы.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге төгәл булып тора.

2.8.4. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Республика порталында һәм Бердәм порталда бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза тапшырганда көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.

2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да

2.13.1. Гариза һәм документлар кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.13.2. Электрон формада Бердәм портал, Республика порталы аша алынган гариза (техник мөмкинлек булган очракта), Бердәм порталда, Республика порталында гаризалар автомат теркәлмәгән очракта, Министрлык тарафыннан алынган көнне билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүче яки аның вәкиле тарафыннан күпфункцияле үзәк аша бирелгән гариза Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гариза күпфункцияле үзәктән алынган көнне теркәлә.

2.13.4. Күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза тапшырылган көнне мөрәҗәгать итүчегә гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган теркәү номеры һәм электрон гаризаны тапшыру датасы белән Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан язу бирелә.

2.13.5. Гаризаны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү) мөмкинлеге тудырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга тоткарлыксыз үтеп керә алу максатларында, түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итә алу үзлеге бозылган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

2) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска ярдәмендә дә;

3) инвалидларга, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, тоткарлыксыз хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен кирәкле җайланмаларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;

4) инвалидлар өчен кирәкле, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны кабатлап тору;

5) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

6) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртә торган этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгында билгеләнгән рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, сукырларны йөртә торган этне кертү.

2.14.3. Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларга һәм дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кулланыла торган, Регламентның 2.14.2 пунктының 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән чаралардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң эксплуатациягә кертелгән яки модернизация, реконструкция узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясында каралган гаризаны (комплексны мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, башкарма

хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәте күрсәтү (шул исәптән тулы күләмендә) мөмкинлеге яки андый мөмкинлекнең булмавы

2.15.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документлар кабул ителә, бирелә торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

2) белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

3) мәгълүмат стендларында, башкарма комитетның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;

4) инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулаган каршылыкларны үтәргә ярдәм итү;

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;

3) опека һәм попечительлек органы хезмәткәрләре тарафыннан Регламент бозылуына карата нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы;

4) мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлек итү саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кирәкле барлык документлар белән гариза биргән вакытта мөрәҗәгать итүче бер тапкыр күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре белән үзара хезмәттәшлек итә;

4.2) күпфункцияле үзәктә дәүләт хезмәте күрсәтүнең электрон документ формасындагы нәтиҗәсен кәгазьдә алу зарурлыгы булган очракта, – бер тапкыр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бер мәртәбә үзара хезмәттәшлек итүнең вакыт озынлыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, терминал җайланмаларыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә хокуклы.

2.15.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда яки Республика порталында шәхси кабинеттан, күпфункцияле үзәктән, Министрлыкта алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм башка документлар турындагы белешмәләрдән файдалану мөмкинлеге, алдан авторизация узмыйча гына, Порталдагы «шәхси кабинет» аша гамәлгә ашырыла. Авторизация узганнан соң, мөрәҗәгать итүче Порталдагы «Шәхси кабинеты» аша түбәндәге мөмкинлекләргә ия була: Портал аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документны бирү; кирәк булган очракта дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен (график файлларны) теркәү; дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында белешмәләр алу; дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алу.

2.15.4. Дәүләт хезмәте, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, аның яшәгән урынына яки фактта яшәгән (торган) урынына бәйсез рәвештә, теләсә кайсы күпфункцияле үзәктә экстерриториаль принцип буенча күрсәтелә.

Комплексны мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны, гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән, Бердәм порталда һәм Республика порталында шәхси кабинет аша электрон документ формасында тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм порталдан һәм Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон белдерү формасында алырга;

е) Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә башкарма комитет, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны электрон форматта бирү мөмкинлеген тәэмин итү өчен, мөрәҗәгать итүчедә гади электрон имза ачкычы булырга тиеш. Гади электрон имза ачкычын (алга таба – гади электрон имза) алу өчен мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү процедурасын узарга кирәк. ИАБС системасында алдан теркәлүнең онлайн-формасы «Интернет» челтәрендәге сайтта урнаштырылган («Интернет» челтәрендәге сайтның домен исеме – ecia.gosuslugi.ru/).

ИАБС системасында (физик зат буларак) теркәлү процедурасын узганнан соң мөрәҗәгать итүче – физик зат гади электрон имзаны кулланып Порталда авторизация узарга тиеш. Порталдагы «Шәхси кабинет»та авторизацияләнгәннән соң мөрәҗәгать итүче элек бирелгән гаризаларын һәм хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү нәтиҗәләрен карау мөмкинлеген ала.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Мөрәҗәгать итүчеләрне күпфункцияле үзәктә кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язылу) Республика порталы аша, күпфункцияле үзәкнең элемтә үзәге телефоны буенча гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу вакыты әлеге дата башланырга бер тәүлек калгач бетә.

Бердәм портал һәм Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Кабул итүгә алдан язылган вакытта билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

2) мөрәҗәгать итүчене кабул итү, документлар кабул итү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турында карар кабул итү яисә бер тапкыр пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турында карар кабул итү;

5) баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие түләү;

6) техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүе административ процедураны башкару өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып түбәндәгеләр тора:

мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә – күпфункцияле үзәк хезмәткәре;

мөрәҗәгать итүче Министрлыкка мөрәҗәгать иткән очракта – дәүләт хезмәте күрсәтү вазыйфаи бурычларына карый торган Министрлык хезмәткәре (алга таба – консультацияләү өчен җаваплы вазыйфаи әат; опека һәм попечительлек органы хезмәткәре).

3.2.2. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация сорап шәхсән үзе һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә дә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләү.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка телефон һәм электрон почта буенча мөрәҗәгать итәргә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле башка мәсьәләләр буенча да, Республика порталыннан, Министрлык сайтыннан консультация алырга хокуклы.

Консультацияләр бирүгә җаваплы вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә Регламентның 1.3.3 пункты таләпләре нигезендә мәгълүмат җиткерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның составы, формасы буенча һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләр.

3.3. Мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карау

3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны күпфункцияле үзәк аша кабул итү.

3.3.1.1. Мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.3.1.2. Гаризаларны кабул итүче күпфункцияле үзәк хезмәткәре:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый;

мөрәҗәгатьнең предметын билгели;

документлар тапшыручы затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

күпфункцияле үзәкнең автоматлаштырылган системасында гаризаның электрон формасын тутыра;

Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазьдә тапшырылган очракта, тапшырылган документларны сканер аша уздыра;

күпфункцияле үзәкнең Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан гаризаны бастырып чыгара;

тикшереп чыгу һәм имзалау өчен мөрәҗәгать итүчегә бирә;

имзаланганнан соң имзаланган гаризаны күпфункцияле үзәкнең Автоматлаштырылган мәгълүмат системасына сканер аша кертә;

электрон формада тапшырылган документларны яки документларның сканер аша уздырылган электрон үрнәкләрен күпфункцияле үзәкнең Автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертә, электрон эш формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның оригиналларын кире кайтара;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү буенча язу бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: җибәрүгә әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3. Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән электрон формадагы (электрон эшләр пакетлары составында) документлар пакетын мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәкнең структур бүлекчәсенә мөрәҗәгать иткән көннән башлап бер эш көне эчендә Министрлыкка тапшыра.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Министрлыкка җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон эш).

3.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Республика порталы һәм Бердәм портал аша электрон формада кабул итү.

3.3.2.1. Республика порталы, Бердәм портал аша электрон формада гариза тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында һәм Бердәм порталда авторизацияләнә;

Республика порталында һәм Бердәм порталда гаризаның электрон формасын ача;

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә риза булуын раслый (электрон гариза формасында тиешле билге билгели);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза белән һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Министрлыкка җибәрелгән электрон эш.

3.3.3. Министрлык тарафыннан документлар комплектын карау.

3.3.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларның алынуы административ процедураны үти башлау нигезе булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып Министрлык хезмәткәре (алга таба – документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

Документлар карау өчен алынганнан соң документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм «Документларны тикшерү» статусын беркетә, ул Республика порталындагы һәм Бердәм порталдагы шәхси кабинетта чагылдырыла;

алынган электрон эшләрне, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон формада теркәлгән документларны һәм документларның электрон үрнәкләрен өйрәнә;

документларның электрон үрнәкләренең комплектлылыгын, укылышлы булуын тикшерә;

Республика порталына һәм Бердәм порталга керү юлы белән, электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (әгәр мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон үрнәкләре тапшырылган булса).

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты әзерли (4 нче кушымта).

Документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп (әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре мондый документларга карата куелган таләпләрне бозуга бәйле булса, документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карарда тапшырылмаган, төгәл булмаган һәм (яки) каршылыклы мәгълүматларны үз эченә алган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документларның (мәгълүматның, белешмәләрнең) исемнәре турындагы мәгълүматны үз эченә алырга тиеш), электрон документ әйләнеше системасында теркәлә һәм Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана, гариза алынган көннән башлап бер эш көне узганчы Республика порталында, Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

Документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен аңлатып, опека һәм попечительлек органының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан теркәлә һәм имзалана һәм мөрәҗәгать итүчегә почта аша (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша мөрәҗәгать итүченең Республика порталындагы, Бердәм порталдагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә гаризаның алынуы турында теркәү номеры, гаризаны алу датасы, үзенә килгән документларның файллары атамалары исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу датасы күрсәтелгән белдерү җибәрә.

3.3.3.2. Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.3.3.3. Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар Министрлыкка кергән көндә яисә, гариза һәм документлар Министрлыкның эш вакыты тәмамланганнан соң кергән булсалар, киләсе эш көнендә гамәлгә ашырыла. Гариза һәм документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – опека һәм попечительлек органының ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза һәм документлар яки мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылган документлар.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү

3.4.1. Административ процедура үтәлеше өчн вәкаләтле вазыйфаи затның (хезмәткәрнең) документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи заттан

(хезмәткәрдән) мөрәҗәгать итүчедән кабул ителгән документларны алуы административ процедура үтәлешен башлап җибәрү нигезе булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып Министрлык хезмәткәре (алга таба – ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

3.4.2. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат, Регламентның 2.6.1 пунктында каралган документларны һәм белешмәләрне бирү турында электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыра һәм ведомствоара электрон багланышлар системасы аша (техник мөмкинлек булмаса – башка ысуллар белән) җибәрә.

Әлеге пунктта белән билгеләнә торган административ процедуралар гариза карау өчен кабул ителгән көнне башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларга җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.3. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр (алга таба – документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар законнарда билгеләнгән чорда гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар (белешмәләр), яисә баш тарту турында ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка юлланган белдерү.

3.4.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи зат ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша соратып алына торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны (белешмәләрне) яисә, документ һәм (яки) мәгълүмат булмаса, баш тарту турында белдерү ала.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы булган вазыйфаи заттан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар комплектының (белешмәләрнең) алынуы административ процедура үтәлешен башлап җибәрү нигезе булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат булып дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат тора.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы белгеч:

3.5.2.1. Министрлыкка мөрәҗәгать иткән очракта:

1) тапшырылган документларны һәм рәсми мөрәҗәгатьләргә җавапларны, мөрәҗәгать итүченең шәхси сыйфатларын һәм мотивларын, аның баланы тәрбияләүгә карата сәләтен, мөрәҗәгать итүче гаиләсендәге әгъзалар арасында барлыкка килгән мөнәсәбәтләрне тикшерә.

2) баланы гаиләгә тәрбиягә бирү турында бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турында карар яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар әзерли, имзалау өчен җитәкчегә (ул вәкаләт биргән затка) җибәрә (2 нче кушымта).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедуралар тәмамлангач 3 календарь көне дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: 1) җитәкчегә (ул вәкаләт биргән затка) имзалау өчен җибәрелгән, баланы гаиләгә тәрбиягә бирү турында бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турында карар проекты яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты (3 нче кушымта).

3.5.2.2. гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар Министрлыкка күпфункцияле үзәк аша яки Республика порталы, Бердәм портал аша алынган очракта

1) алынган электрон эшләрне һәм рәсми мөрәҗәгатьләргә җавапларны, мөрәҗәгать итүченең шәхси сыйфатларын һәм мотивларын, аның баланы тәрбияләүгә карата сәләтен, мөрәҗәгать итүче гаиләсендәге әгъзалар арасында барлыкка килгән мөнәсәбәтләрне тикшерә.

2) баланы гаиләгә тәрбиягә бирү турында бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турында карар яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар әзерли, имзалау өчен җитәкчегә (ул вәкаләт биргән затка) җибәрә (2 нче кушымта).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедуралар тәмамлангач 3 календарь көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзалау өчен җитәкчегә (ул вәкаләт биргән затка) җибәрелгән, баланы гаиләгә тәрбиягә бирү турында бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турында карар яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар.

3.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турындагы карар проектын, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе проектын (алга таба – документларның проектлары) килештерү һәм имзалау җитәкче (ул вәкаләт биргән зат) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Документларның әзерләнгән, кисәтүләре булган проектлары эшләп бетерү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи затка кире кайтарыла. Кисәтүләре бетерелгәннән соң, документларның проектлары янә килештерү һәм имзалау өчен җибәрелә.

Административ процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәте күрсәтү турында имзаланган карар, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар.

3.5.4. Регламентның 3.5.3 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документларның административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан алынуы административ процедураны үти башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи зат булып документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы зат (алга таба – документларны бирү (җибәрү өчен җаваплы зат) тора.

Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат:

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турындагы белешмәләрне терки һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасының документлар кертелә торган ярдәмче системасына кертә;

Республика порталы, Бердәм портал аша электрон хезмәттәшлек итү юлы белән мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә, Министрлыкта алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документ вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан имзаланган көнне башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: мәгълүмат системаларында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен бирү (җибәрү) тәртибе:

3.6.2.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе артыннан күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткән очракта, күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирә. Мөрәҗәгать итүче таләбенә карап, кәгазьдәге электрон документ нөсхәсе белән аңа, алына торган саклагыч җайланмага яздыру юлы белән, электрон документ нөсхәсе дә бирелә ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар чират тәртибендә, мөрәҗәгать итүче килгән көнне күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документны Республика порталын кулланып җибәрү (бирү).

3.6.2.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның опека һәм попечительлек органының вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвеше мөрәҗәгать итүчегә автомат рәвештә шәхси кабинетка җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документ опека һәм попечительлек органының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган көнне башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документны Республика порталын, Бердәм порталны кулланып җибәрү (бирү).

3.6.2.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе артыннан Министрлыкка мөрәҗәгать иткән очракта, Министрлык хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазьдә электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документ вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан имзаланган көнне башкарыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документны Республика порталын, Бердәм порталны кулланып җибәрү (бирү).

3.7. Техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

Бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турындагы карарны (бер тапкыр пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы карарны) яңадан рәсмиләштерү бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турындагы карарда (бер тапкыр пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы хатта) җибәрелгән техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) бетерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турындагы карарны (бер тапкыр пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы карарны) яңадан рәсмиләштерү техник хатасы булган, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган документ (мондый документ бирелгән очракта) белән теркәлгән гариза (гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка 5 нче кушымтада китерелә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.1. Министрлык белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки;

бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турындагы карарны (бер тапкыр пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы карарны) яңадан рәсмиләштерә;

бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турындагы үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны (бер тапкыр пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы карарны) имзалау өчен җитәкчегә (ул вәкаләт биргән затка) җибәрә;

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турында (бер тапкыр пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турында) җитәкчегә (ул вәкаләт биргән затка) имзалау өчен юнәлдерелгән, яңадан рәсмиләштерелгән карар проекты.

3.8.2. Җитәкче (ул вәкаләт биргән зат) бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турындагы (бер тапкыр пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы) яңадан рәсмиләштерелгән карарны раслый, имзалый һәм мөһер белән таныклый һәм аны Министрлык белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турындагы (бер тапкыр пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турындагы карар) карарны имзалау өчен җибәргәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турында (бер тапкыр пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар. Министрлык белгече мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турында (бер тапкыр пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында гаризада күрсәтелгән ысул белән хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн дәвамында башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турында (бер тапкыр пособие билгеләүдән һәм түләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен башкаруга таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклаудан һәм бетерүдән, дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә тикшерүләр уздырудан, карарлар кабул итүдән һәм опека һәм попечительлек органының вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләүдән тора.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре булып түбәндәгеләр тора:

дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документларның проектларына хокукый экспертиза уздыру. Экспертизалар нәтиҗәсе булып проектларга имза салу тора;

дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документларның проектларын тикшерү һәм килештерү;

эшчәнлек алып барылышына карата билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган тикшерүләр;

дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Административ процедураларның срокларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында вазыйфаи затлар кичекмәстән дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплы министр урынбасарына хәбәр итәләр, шулай ук җитешсезлекләрне бетерү буенча ашыгыч чаралар күрелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контрольлек дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган белгеч, эш башкару хезмәте белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге опека һәм попечительлек органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру тәртибе һәм аларның ешлыгы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына контрольлек тәртибе һәм формалары.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырылганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгатенә бәйле мәсьәләләр каралырга мөмкин.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органдагы вазыйфаи затларның дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен җаваплылыгы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә һәм карарлар кабул ителгәндә гамәлләр кылуны тикшереп тору максатларында опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар тапшырылырга мөмкин.

Административ процедураларның сроклары, эзлеклелеге һәм эчтәлеге бозылу очраклары һәм сәбәпләре турында белгечләр кичекмәстән дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган җитәкчесенә хәбәр итә, шулай ук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрә.

Җитәкче мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында каралуын контрольдә тота.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгән кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр өчен җаваплы башкаручылар законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы була.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да, контроль тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне сыйфатлый торган нигезләмәләр.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә опека һәм попечительлек органы эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү

барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

**5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе**

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр башкарма комитет хезмәткәрләренең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесенә, муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) муниципаль берәмлек башлыгына судка кадәр тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны

һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, муниципаль берәмлекнең рәсми сайты, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьне карау срогы – аны теркәгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, органдагы вазыйфаи затның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яисә хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яки мондый төзәтмәләрне кертү чоры бозылганда, – аны теркәгән көннән башлап биш календарь көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә граждан хезмәткәренең яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон

номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, Башкарма комитетта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм, дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында, алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Опека һәм попечительлек органы, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына.

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган форма

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына

_______________________________________,

(законлы вәкилнең яки ышанычлы затның Ф.И.А (булган очракта))

яши торган (теркәлү) адресы:

_______________________________________

_______________________________________

Факттагы яшәү адресы ___________________

_______________________________________

паспорт: серия ________ номер _____________

бирелгән «____» ___________________________

_______________________________________

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турында

ГАРИЗА

Миңа баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләвегез турында үтенәм

______________________________________________________________________

(баланың фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта))

Пособиене күрсәтелгән ысулларның берсе ярдәмендә түләвегезне сорыйм:

кредит оешмасына күчерергә ________________________________________________

______________________________________________________________________

(пособие күчерелергә тиешле оешманың атамасы,

банк идентификация коды (БИК), салым түләүченең идентификация номеры (ИНН) һәм оешманың урнашкан урыны буенча салым органында исәпкә алганда бирелгән исәпкә кую сәбәбе коды (КПП),, пособиеләрне алырга хокукы булган затның счет номеры)түбәндәге адрес буенча җиткерергә ______________________________________________.

(адрес, почта элемтәсе оешмасы)

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1. ______________________________________________________________

2. ______________________________________________________________

3. ______________________________________________________________

4. ______________________________________________________________

(дата) (имза)

Гариза законлы вәкил яки ышанычлы зат аша тапшырыган очракта, гаризада өстәмә рәвештә түбәндәгеләр күрсәтелә:

______________________________________________________________

(законлы вәкилнең (ышанычлы затның) фамилиясе, исеме, ата исеме, яшәү урыны (тору урыны, фактта яшәү урыны) почта адресы)

______________________________________________________________

(законлы вәкилнең (ышанычлы затның) шәхесен таныклаучы документның атамасы, номеры һәм сериясе)

______________________________________________________________

(законлы вәкилнең (ышанычлы затның) шәхесен таныклаучы документны биргән оешма һәм аны бирү датасы турында белешмәләр)

______________________________________________________________

(законлы вәкилнең (ышанычлы затның) вәкаләтләрен раслый торган документның атамасы, номеры һәм сериясе)

______________________________________________________________

(законлы вәкил (ышанычлы зат) вәкаләтләрен раслый торган документны биргән оешма һәм аны бирү датасы турында белешмәләр)

____________ ______________________________________________

(дата) (законлы вәкил, ышанычлы зат имзасы)

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Кемгә

___________________

_____________________

# КАРАР

«Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү» хезмәте күрсәтү турында

_______________№ ______________

____________________ № _______ гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча, «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» 1995 елның 19 маендагы 81-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Хезмәт министрлыгының «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре билгеләү һәм түләү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2020 елның 29 сентябрендәге 668н номерлы боерыгы нигезендә әлеге баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү карары кабул ителде:

_________________________________________________________________________________

(Фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, ае, елы)

____________________ сум күләмендә.

---

Дата Имза

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Форма

**Кемгә** _______________

_________________________________

«Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү» хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында
КАРАР

__________________________№ __________________

____________________ № ______ гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча, «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» 1995 елның 19 маендагы 81-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Хезмәт министрлыгының «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре билгеләү һәм түләү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2020 елның 29 сентябрендәге 668н номерлы боерыгы нигезендә әлеге баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде, түбәндәге нигезләр буенча:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Хезмәт күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен аңлату:

Әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән Сез вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

______________________________________________________________________________

Дата Имза

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Форма

Кемгә ________________________

________________________________

________________________________

«Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү» хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында
КАРАР

___________________№______________________

____________________ № ______ гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карау нәтиҗәләре буенча, «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» 1995 елның 19 маендагы 81-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Хезмәт министрлыгының «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре билгеләү һәм түләү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2020 елның 29 сентябрендәге 668н номерлы боерыгы нигезендә хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде, түбәндәге нигезләр буенча:
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________

Документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен аңлату:

Әлеге җитешсезлекләрне бетергәннән соң хезмәт күрсәтү турында гариза белән Сез вәкаләтле органга кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Баш тарту турындагы әлеге карарга вәкаләтле органга шикаять җибәрү юлы белән – судка кадәрге тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә дә, шикаять бирелергә мөмкин.

_________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________
Дата Имза

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына

5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына

_______________________________________________,
(законлы вәкилнең яки ышанычлы затның Ф.И.А (булган очракта))
яши торган адресы:
_______________________________________________
_______________________________________________
паспорт: серия ________ номер _____________
бирелгән «____» _____________________________
_______________________________________________

Киңәш ителә торган форма

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин,_______________________________________________________________________
*(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)*

яши торган адрес: ____________________________________________________________

_____________________________________________________________________________

*(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)*

_____________________________________________________________________________

*(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ атамасы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы,*

_____________________________________________________________________________
*документны биргән орган атамасы)*

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү турында ______________ № __________ карарда җибәрелгән ____________________ техник хатаны төзәтүегез турында үтенәм

_________ № ______________

Техник хатаны төзәтү турында карарны түбәндәгечә алуга риза

_____________________________________________________________________________
*(язмача, телефон аша, смс-хәбәр белән, электрон почта аша)*

«___» _____________ 20___ ел. ____________________ __________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)

Баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырганда бер тапкыр пособие билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

## Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен һәм аны күрсәткәндә агымдагы контрольлек өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның реквизитлары

### Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 294-95-90 | Ilsur.Hadiullin@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 294-95-02 | Alsu.Asadullina@tatar.ru |
| Опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге җитәкчесе | 294-95-66 | Venera.Vasileva@tatar.ru |

### Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге җитәкчесе | 264-77-20 | Andrey.Vybornov@tatar.ru |